МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ № 106/о БОЕРЫК

"21" 08 2019

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 01 февралендәге 17/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәнең 4 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау турында» 2017 елның 01 февралендәге 17/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 11 октябрендәге 180/о номерлы, 2018 елның 21 июнендәге 107/о номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәнең 4 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче кушымтаның Дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар тарафыннан Татарстан

Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлегенең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Хосусый (шәхси) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ күчермәсе.»;

Дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар тарафыннан Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге кушымтасында «дәүләт пенсия иминиятенең иминиятләштерү таныклыгы номеры» дигән сүзләрне «хосусый (шәхси) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ;» дигән сүзләр белән алмаштырырга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы мөдире Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА